СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.07.2021 г. Заинск № 64

**«Зәй муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» 2019 елның 14 октябрендәге 442 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмә хакында» 2019 елның 14 октябрендәге 442 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 бүлекнең 2 абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 20 бүлекнең 14 абзацында «средстволарны исәпкә алу буенча» сүзләрен «җирле» сүзенә алмаштырырга;

1.3. 27 бүлекнең 2 пунктында «һәм башкарыла» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 32 бүлекнең 4 пунктында «һәм башкарыла» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5. 32 бүлекнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гарантның принципалга регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия белән акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты район (Гарант), мөлкәте район (Гарант) милкендә булган муниципаль унитар предприятиенең (Гарант) йөкләмәләре генә тәэмин ителергә мөмкин, ә гарантның принципалга регресс таләбе хокукын күздә

тотмый торган Россия Федерациясе дәүләт гарантиясе белән, шулай ук дәүләт корпорациясе яисә Россия Федерациясе тарафыннан гамәлгә куелган (төзелгән) дәүләт компаниясе йөкләмәләре тәэмин ителергә мөмкин.»

1.6. 32 бүлекнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Кредит (заем, шул исәптән облигация буенча) буенча принципал йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия гарантның ризалыгыннан башка үзгәртелергә тиеш булмаган гарантның муниципаль гарантиядә күрсәтелгән төп йөкләмә шартлары гарантның алдан язмача ризалыгыннан башка үзгәргән очракта гына гарант тарафыннан кире алына һәм (яисә) кредит акчаларын (займ, шул исәптән облигация) максатсыз файдалану очрагында, аңа карата Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль гарантия бирү турында шартнамә нигезендә кредит акчаларыннан максатчан файдалануны контрольдә тоту гамәлгә ашырыла.»;

1.7. 32 бүлекнең 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

1.8. 38 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38. Бюджет keremнәрен фаразлау

Бюджет керемнәре район бюджеты турында карар проектын район Советына кертү көненә гамәлдә булган районның социаль-икътисадый үсеш фаразы һәм шулай ук район бюджетының салым булмаган керемнәрен билгели торган күрсәтелгән датага кабул ителгән һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында үз көченә кергән салымнар һәм җыемнар турында законнар, Россия Федерациясе Бюджет законнары, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм район Советының муниципаль хокукый актлар нигезендә фаразлана.

Район Советының җирле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турында карар проекты кертелгәннән соң кабул ителгән муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында, агымдагы финанс елына һәм план чорына, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә, исәпкә алына.»;

1.9. 53 бүлекнең 5 абзацында «касса» сүзен «казначылык» сүзенә алмаштырырга.

2. Район Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**